# Без көрәшле һәм батыр халык

**22-23 ноябрьдә Казанда көрәш буенча Татарстан чемпионаты узды.**

Энҗе ГАБДУЛЛИНА

### КАДАДЫЛАР...

Бу ярышта да күп кенә җиңүләр һәм җиңелүләр алым ясап түгел, ә аркага яткан һәм аркага яткырган өчен булды. Соңгы ике елда көрәштә кагыйдәләр үзгәртелгәч, болар гадәти күренешкә әверелде бит. Шуңа күрә көрәшчеләр элеккеге кебек көндәшен күтәреп атарга ашыкмый, чөнки аркага яткан өчен кисәтү аласылары килми. Хәзер тота да көндәшен башы белән кадап куя.

Кагыйдәләрне үзгәртү аркасында инде күпме җәрәхәт алдылар. Газиз балаңны ничек курыкмыйча келәмгә кертеп җибәрергә? Балалар көрәшкә килми дибез. Муенсыз һәм кабыргасыз калганчы, тыныч кына шахмат уйнасын, дип әйтер әти-әниләр.


Татарстан чемпионатында да көндәшен чөеп атып башы белән кадап куючылар булды. Дөрес, көрәш уен уйнау түгел ул. Келәмгә аяк басканда бөтен нәрсәгә дә әзер булырга кирәк. 130 килограммлы Муса Галләмов та ярымфиналда көндәшен башы белән кадап куеп, финалга чыкты бит.

### ФИНАЛ ОЗАККА СУЗЫЛДЫ

Актанышның өмете булган Раббани Нургалиев ышанычныaклады, чемпион калды! Тик ул бу юлы Казанның Вахитов районы командасы (ул хәзерге вакытта шунда шөгыльләнә) өчен чыгыш ясады.

Алексеевск районы өчен билбау көрәшчеләре чыгыш ясады. Барысы да – Казанның Идел буе спорт академиясе укучылары, тренер Бари Сөләймановның шәкертләре. Яңа кагыйдәләр шуларга яраклаштырылган бит инде, көрәшсеннәр рәхәтләнеп! Тик аларның берсе дә чемпион калмады.

75 килограммга кадәрге үлчәү категориясендә Әлмәтнең ике пәһлеваны очрашты – Марат Кәримов белән Рамил Синәкаев. Монда да яңалык юк – өч кисәтү һәм син ирекле! Кыскасы, ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы призын откан Кәримовка икенче урын белән генә канәгатьләнергә туры килде.




С.Камалетдинов фотосы

80 килограммга кадәрге үлчәү авырлыгы финалында Теләче көрәшчеләре очрашты. Берсе – легионер Ренас Кәлимуллин, икенчесе – җирле спортчы Илдар Гыйниятуллин. Соңгысы финалда көрәшеп маташмады, Ренас тиз генә чистага алып салды.

Финалның бик озакка сузылуына 100 килограммга кадәрге үлчәүдә көрәшкән Раил Нургалиев белән Булат Мусин сәбәпче булды. Озак маташтылар да соң. Бер-берсенең билбауларын тоталмыйча йөрделәр. Хөкемдарлар чакырып китереп, үзләрен өйрәтеп тә карады. Һәм, ниһаять, көрәшчеләргә җан керде! Кыскасы, Нургалиев булдырды, Мусин оттырды.

Беренче көнне кәмит ясап, халык теленнән төшмәгән Радик Сәлахов икенче көнне бик тыныч иде. Тамашачыларга карап, ямьсез ишарәләр ясаган Сәлаховны ярыштан төшереп калдырмадылар. Гаебен тулысынча таныган, гафу да үтенде.

Кыскасы, чемпионатның тәүге көнендә 130 килограммга кадәрге үлчәү авырлыгында Әлмәт данын яклаган Радик Сәлахов белән Казанның Вахитов районы өчен көрәшкән Лениз Абдуллин очрашкан иде. Лениз исәп буенча отып барды, тик Радик Ленизны аркасына яткырып, өченче кисәтү алдырып, өстен чыкты. Бу хәл халыкка ошамады. Бер алым да күрсәтмичә җиңде, дөрес түгел, диделәр. Хөкемдарлар көрәшчеләрне янә келәмгә чакырды. Әлеге алыш Радикның җиңүе белән тәмамланды. Шул чакта аның тамашачыларга карап ямьсез ишарәләр ясавы халыкның хәтерен калдырды.

Финалда Радик Сәлахов Муса Галләмов белән очрашты. Муса шәп көрәште. Халык шундыйларны ярата бит. Аңа дәррәү кул чаптылар. Хәзер кайсы алышның чын алыш икәнлеген халыкның кул чабуыннан аңлап була.

130 килограммнан югарырак үлчәү авырлыгында Питрәч данын яклаган Фәрхәт Фәйзуллин җиңү яулады. Ул финалда Фирдүс Зәйнуллинны отты.

Гомуми баллар буенча Теләче – беренче, Әлмәт – икенче, Кукмара вәкилләре өченче урынны яулады. Теләчеләр дүртенче ел рәттән Татарстан чемпионатында беренчелекне бирми. Кукмара да мактауга лаек, чөнки район өчен Кукмара егетләре генә көрәште.

КУЛЛАНУЧЫ ХӘБӘРЛӘРЕ

## УЕНЧЫК САЙЛЫЙ БЕЛӘСЕМЕ?

**Балалар продукциясен сайлаганда сыйфатка игътибар итәргә кирәк.**

**«Безнең ике балабыз бар: улыбызга – сигез, кызыбызга – ике яшь. Бүген кибетләрдә сатыла торган уенчыклар һәм уеннарның ниндие генә юк. Әмма шуны беләсе килә – аларның барысы да сыйфатлымы, баланың тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырмыйлармы? Кайсы уенчыкларны шикләнмичә сатып алырга мөмкин, ә кайсыларын алмавың хәерле?**

**Поповлар гаиләсе»**

Бүгенге көндә Таможня берлегенең «Балалар һәм яшүсмерләр өчен билгеләнгән продукциянең куркынычсызлыгы турында» һәм «Уенчыкларның куркынычсызлыгы турында»гы Техник регламентлары гамәлдә, алар 2011 елда Таможня берлеге Комиссиясе карары белән расланган. Балалар һәм яшүсмерләргә аталган продукция Таможня берлегенең әгъза-илләре базарына билгеле бер кагыйдәләр нигезендә әйләнешкә чыгарга тиеш. Аның маркировкасы – бердәм тамгасы булуы шарт. Ул эшләнмәнең үзенә, ярлыгына яки кабына төшерелә.

**Өч яшькә кадәрге балалар уенчыгында** мех, фарфор һәм пыяла элементлар, кәгазь һәм катыргы, ворслы резина булмаска тиеш. 3 миллиметрдан да кечкенәрәк төерчекләрнең уенчыкның эчке тышлыгында булуы шарт. Аннан ачы ис килмәскә һәм очлы детальләре булмаска тиеш, үлчәмнәре өске сулыш юлларына эләкмәслек зурлыкта булуы зарур. Уенчыкларның өслеген буярга рөхсәт ителми.

**Эченә әйбер тутырылган йомшак уенчыкның** эчлегендә каты яки очлы әйберләр булмаска, җөйләре нык булырга тиеш.

**10 яшькә кадәрге балалар өчен эшләнгән конструкторлар** һәм җыя торган модельләрдә детальләрне ябыштырып эретү рөхсәт ителми.

**Өстәл һәм бизәкле уенчыкларда** текст һәм рәсемнәрнең төп фонга карата ачык һәм контраст булуы шарт.

**Яктылык диодлары кулланылган уенчыклар** баланың күзенә тискәре йогынты ясамаска, зарарлы нурланыш таратмаска тиеш. Лазерлы нурланыш системаларының барлык төрләрен дә куллану тыела.

**Электрлы уенчыкта** номиналь көчәнеш 24 вольттан да артмаска тиеш, кабель һәм үткәргечләрнең исә изоляцияләнгән булуы шарт.

**Оча торган уенчыкларның шнурлары** металлдан ясалмаска һәм диэлектрик үзлекләргә ия булырга тиеш.



*Әгәр сезгә сыйфатсыз уенчык сатканнар икән, товарда кимчелекләр табылган очракта, «Кулланучыларның хокукларын яклау турында»гы РФ Законы нигезендә товарны алыштыруны яки аның өчен түләнгән акчаны кайтарып бирүне таләп итә аласыз.*

## СЫЙФАТКА ХОКУК

**Сатып алган әйбер «баш авыртуына» әверелмәсен**

**«Кайчагында шулай да була: сатып алган әйбер шатлык та китерми, өстәвенә, «баш авыртуына» әверелә һәм зыян да китерә. Мин, кулланучы буларак, товарларның сыйфаты һәм куркынычсызлыгы турында ниләр белергә тиеш?**

**А.Шагин»**


«Кулланучыларның хокукларын яклау турында»гы РФ Законының 4нче маддәсе нигезендә, сатучы кулланучыга сыйфаты килешүгә тәңгәл килә торган товар тапшырырга тиеш. Әгәр килешүдә товарның сыйфаты турында шартлар күрсәтелмәгән икән, сатучы кулланучыга гадәти таләпләргә туры килә торган һәм билгеле бер максатлар өчен яраклы товар тапшырырга бурычлы.

Кулланучының товарны сатып алуда конкрет максатлары бар һәм ул бу хакта сатучыга хәбәр итсә, сатучы кулланучыга әлеге максатларда куллану өчен товар тапшырырга тиеш. Моннан тыш, сатучы кулланучыга үрнәк яки тасвирламага тәңгәл килә торган товар тапшырырга бурычлы.

Әгәр закон тарафыннан товарга карата мәҗбүри таләпләр күрсәтелсә, сатучы кулланучыга әлеге таләпләргә туры килә торган товар тапшырырга тиеш.

Шуны истә тоту мөһим: Законның 7нче маддәсе нигезендә, кулланучы товарны куллану, саклау, транспортлау һәм утильләштерүнең гадәти шартларында аның кулланучының тормышына, сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохиткә куркыныч тудырмавына, шулай ук кулланучының милкенә зыян китермәвенә хокуклы. Моны тәэмин итәргә тиешле таләпләр билгеләнгән закон тәртибендә мәҗбүри булып тора.

Җитештерүче товарның билгеләнгән хезмәт итү срогы яки яраклылык вакыты дәвамында аның куркынычсызлыгын тәэмин итәргә тиеш. Әгәр срок билгеләнмәгән икән, җитештерүче товарны кулланучыга тапшырган көннән алып ун ел дәвамында аның иминлеген тәэмин итәргә бурычлы. Товарның куркынычсызлыгын тәэмин итмәү нәтиҗәсендә кулланучының тормышына, сәламәтлегенә яки милкенә китерелгән зыян Законның 14нче маддәсе нигезендә капланырга тиеш.




*Моннан тыш, әгәр товарны куллану, саклау, транспортлау һәм утильләштерүдә куркынычсызлыкны тәэмин итү өчен махсус кагыйдәләрне үтәргә кирәк икән, бу очракта җитештерүче аларны товарның документларында, этикеткада, маркировкалау яки башка ысул белән күрсәтергә, ә сатучы әлеге кагыйдәләрне кулланучыга җиткерергә бурычлы.*